Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

12 ноябрь 2020 ел №5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль
районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Танькино авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 26 ноябрендә сәгат 16.00 Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Танькино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының билгеләп үтәргә. Халык җыенын шәхси йортта түбәндәге адрес буенча уздырырга: Танькино авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 8 йорт.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: "Сез яшәү урыны буенча Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Танькино авылы территориясендә теркәлгән көндезге уку бүлегендә укучы студентлар һәм 80 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала һәр балигъ булган яшәүчедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:

- Танькино авылының Кызыл Йолдыз урамы буенча юллардагы чокырларны ремонтлау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек;

- су башнясы өчен насос сатып алу өчен шартлар булдыру кебек эшләр башкаруга юнәлтү белән ризамы?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Түбән Үрәс авыл җирлегенең башкарма комитеты гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында җирлекнең «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә игълан итәргә.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс Авыл
җирлеге башлыгы: Р.Х.Шамеев